**ГЛАВА ШЕМОРБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422667, Республика Татарстан,
Рыбно-Слободский район, с. Шеморбаш,
Советская ул., дом 47,

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ШОМЫРБАШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422667,Татарстан Республикасы,
Балык Бистәсе районы, Шомырбаш авылы,
Совет урамы, 47 нчы йорт.

Тел.: (84361) 20-415, факс: (84361) 20-415, эл.адрес: Smrb.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

15 ноября 2024 года с.Шеморбаш № 3

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шоморбаш авыл җирлеге” Алан-Полян авылы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында.

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “ Шомарбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 25 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Алан-Полян авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыеннарына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Алан-Полян авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме, гәрчә көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, беренче төркем инвалидларыннан, Россия Федерациясе Президенты В.В.Путин тарафыннан игълан ителгән махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнардан, шулай ук аларның гаилә әгъзаларыннан, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү буенча түбәндәге эшләрне башкару:

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, ташу һәм халыкка су бирү системаларын проектлау һәм ремонтлау; Алан-Алан авылында;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- торак пункт территориясен төзекләндерү;

- Алан-Алан авылындагы торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау.

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

3. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Шомарбаш авылы, Совет урамы, 47 йорт; Таулар авылы, Ленин урамы, 50А йорт; Алан-Полян авылы, Я.Емельянов урамы, 6 йорт; Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы авылы, Парк урамы, 10 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомырбаш авыл җирлеге Башлыгы И.Н.Сафин